**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «27» декабреннән №51-399

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс игълан итү турында» 2020 елның 3 ноябрендәге 2-8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы (2023 елның 14 апрелендәге үзгәрешләр белән) федераль законнар, Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» 2023 елның 25 маендагы 332 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2020 елның 3 ноябрендәге 2-8 номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 26 маендагы 34-277 номерлы карары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән Контрактка (алга таба - Контракт) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Контрактның 3.2.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.6. Район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларын, Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнары җитәкчеләрен билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә, алар арасындагы вазыйфаларны бүлешә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм Башкарма комитетның башка хезмәткәрләрен вазыйфаларыннан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы белән алдан килештереп, бүләкләү һәм түләтү чараларын (устав нигезендә) куллана;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Бвшлыгы В. М. Козлов